ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШУМКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422653, с. Шумково,
ул. Центральная, дом 4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУМКОВО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422653, Шумково,
Үзәк урамы, 4 нче йорт,

Тел.: (84361) 26332, факс: (84361) 26332, e-mail:smk.rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

2021 елның 29 гыйнвары Шумково авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегендә җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм "Җирләү һәм мәет кую эше турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 маддәсендәге 3 пунктын, 12 маддәсендәге 3 пунктын, "Татарстан Республикасында җирләү һәм мәет кую эше турында" Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарының 3 пунктынүтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Пенсия фондының 2021 елның 13 гыйнварындагы "2021 елның 1 февраленнән Россия Пенсия фонды тарафыннан гамәлгә ашырыла торган индексацияләү турында"гы СЧ-25-24/270 номерлы хатына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авылҗирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлегенигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1, 2 нче кушымталар нигезендә 6424,98 сумкүләмендә билгеләргә һәм 2021 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында" 2020 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарын 2021 елның 1 февраленнәнүз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Шумково авылы, Үзәк урамы 4 нче йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Укмас авылы, Үзәк урам, 42 нче йорт; Татарстан

Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы, Хутор авылы, Молодежная урамы, 5 нче йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Әшнәк-Качкалак авылы, Югары 5 нче йортында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Башлыгы Л. М. Нәҗмиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Шумково авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021 елның 29 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
кушымта №1

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районының Шумково авылҗирлегендә**
**2021елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую)буенча хезмәтләрнең**
**гарантияле исемлегенигезендә күрсәтелә торган**
**хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәмкитерү | 1966 |
| 3.Мәетне (мәрхүмнеңҗәсәден) зиратка (крематорийга) күчерү(алып бару) | 975 |
| 4. Җирләү (мәетнеяндыру, соңыннан көлеса лынга нурнаны бирү белән) | 3483,98 |
| Җәмгысе: | 6424,98 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Шумково авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2021 елның 29 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
кушымта № 2

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегендәире (хатыны), якынтуганнары, бүтәнтуганнарыя исәмәрхүмнеңзаконлывәкилебулмаганда яки алартарафыннанмәет куюныгамәлгәашырумөмкинбулмагандаисәҗирләүбурычынүзөстенә ала торганбашка затбулмаганда, мәет кую буенчахезмәтләрнеңгарантияләнгәнисемлегебуенчатүләүсезнигездә(бушлай) күрсәтеләторганхезмәтләрнеңбәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетнекәфенләү | 542 |
| 3. Табутны һәм җирләүөчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 1424 |
| 4. Мәетне (мәрхүмнеңҗәсәден) зираткакүчерү (алып бару) | 975 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәмкүмү) | 3483,98 |
| Җәмгысе: | 6424,98 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Башлыгы Л. М. Нәҗмиев